**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА, УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ,
44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-36-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

19.10.2023 ел №105

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар булмаса, закон буенча да, васыять буенча да, яки варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яисә барлык варислар да мирас алудан читләштерелгән, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки варисларның барысы да мирас алудан баш тарткан һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

2) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

3) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

4) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 һәм 47 статьяларының 1 өлешендәге 3,4 пунктларына

ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы тарафыннан карар чыгару;

5) салым түләүче физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы (өлкәннәр, инвалидлар, яшь инвалидлар, инвалид балалар, сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен интернат - йортларда;

- интернат-йортларда, шул исәптән психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар йортларында;

- махсус интернат-йортларда, шул исәптән картлар һәм башкалар өчен) җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә;

6) ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютта тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затлар;

7) җирле үзидарә органнарының раслаучы документлары булган очракта аз керемле физик затлар;

8) психик тайпылышлары булган, суд карары яки җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танылган физик затлар;

9) ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган физик затлар, суд карары нигезендә иректән мәхрүм итү урыннарында булу чорына.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

ТР Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2023 елның 16 мартындагы № 83 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (parvo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф.Митякин